КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 апрель г.Казань № 360

Татарстан Республикасының аерым социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының ятак фондын һәм хезмәткәрләренең иң чик штат санын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен, шул исәптән балалар өчен, интернат йортларның исемен үзгәртү турында» 2026 ел, 18 октябрь, 820 нче карары кабул ителүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның тибын үзгәртү һәм бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре мөлкәтен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

«Югары Утар балаларга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт казна учреждениесенең ятак фонды 80 стационар ятак урыны, «Дербышка балаларга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт казна учреждениесенең ятак фонды 210 стационар ятак урыны тәшкил итә;

«Югары Утар балаларга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат саны 121,78 штат берәмлеге, «Дербышка балаларга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат саны 235,4 штат берәмлеге тәшкил итә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин